ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

423739, Качкын авылы,
Үзәк ур., 37в нчы йорт.
Тел.: 3-44-63
email: usin.akt@tatar.ru

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423739, д.Качкиново,
ул.Центральная, д.37в.
Тел.: 3-44-63
email: usin.akt@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «16» март 2020 ел. №7

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Усы авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Усы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлегенең башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче З.З.Ахмаев

Татарстан Республикасы Актаныш
муниципаль районының Усы авыл
җирлеге башкарма комитетының
16.03.2020ел №7 нче карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Усы авыл җирлеге башкарма комитетка кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлегенең башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш муниципаль районының Усы авыл җирлеге башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау карау, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын яхшырту максатларында уздырыла.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау барлык мөрәҗәгатьләр буенча, шул исәптән язма рәвештә дә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү юлы белән электрон документ рәвешендә, шулай ук гражданнарны кабул итү барышында вәкаләтле затлар тарафыннан кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитетының секретаре гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча хисап чорыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә гражданнарны шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнар шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар турында мәгълүмат (булган очракта) булырга тиеш.).

7. Җирле үзидарә органына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау алдагы елның шушы чорына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге башкарма комитетының секретаре “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.rub “Гражданнар мөрәҗәгатьләре” бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр "Гражданнар мөрәҗәгатьләре" бүлегендә ел саен аналитик белешмә урнаштыруны тәэмин итә.